1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2020 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: Олы Бәрәзә авыл территориясен чистарту һәм төзекләндерү, агачларны кистерү һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;басманы төзекләндерү, төзелеш кирәк-ярагын алу һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; зиаратны төзекләндерү һәм карап тору өчен чыгымнар тоту; авыл эчендәге юлларны карап тоту өчен чыгымнар тоту һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; урам утларын карап тоту, лампочкалар алу өчен чыгымнар тоту" мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Фатыхова А.В.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1021606155405
Совет Нижнеберескинского сельского Поселения
ИНН 1610000476 КПП 161001001

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеген Олы Бәрәзә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“16” ноябрь 2019 ел.

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 10 ноябрендә «Сез 2020 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.- Олы Бәрәзә авыл территориясен чистарту һәм төзекләндерү, агачларны кистерү һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

- басманы төзекләндерү, төзелеш кирәк-ярагын алу һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

2. Зиаратны төзекләндерү һәм карап тору өчен чыгымнар тоту;

3. Авыл эчендәге юлларны карап тоту өчен чыгымнар тоту һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

4. Урам утларын карап тоту, лампочкалар алу өчен чыгымнар тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 414 (дүрт йөз ундүрт) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 340 ( өч йөз кырык ) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 340 ( өч йөз кырык ) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте: